| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 24 » июль 2019 с. Тюлячи № 443

Теләче муниципаль районында яшәүче гражданнарның социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләрен хәл итү, реаль керемнәрен арттыру буенча эшче төркем төзү турында

Теләче муниципаль районы социаль яклау бүлеге начальнигының 2019 елның 11 июлендәге 38 номерлы хатын караганнан соң, РФ Президентының «2024 елга кадәр Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары һәм стратегик бурычлары турында»гы 2018 елның 7 маендагы 204 номерлы Указын тормышка ашыру өчен, Татарстан Республикасында 2024 елга гражданнарның реаль керемнәрен арттыру, ярлылык дәрәҗәсен ике тапкыр киметүгә юнәлдерелгән сынау проектын тормышка ашыру кысаларында,

КАРАР БИРӘМ:

1. Теләче муниципаль районында яшәүче гражданнарның социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләрен хәл итү, реаль керемнәрен арттыру буенча эшче төркем төзергә.
2. Теләче муниципаль районында яшәүче гражданнарның социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләрен хәл итү, реаль керемнәрен арттыру буенча эшче төркем турында нигезләмәне 1нче кушымта нигезендә расларга.
3. Теләче муниципаль районында яшәүче гражданнарның социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләрен хәл итү, реаль керемнәрен арттыру буенча эшче төркем составын 2нче кушымта нигезендә расларга.
4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Җитәкче урынбасары – Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш һәм инвестиция эшчәнлеге бүлеге начальнигы И.Ә. Миннигуловка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның «24» июль
443 номерлы карары белән
расланган 1нче кушымта

**Теләче муниципаль районында яшәүче гражданнарның социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләрен хәл итү, реаль керемнәрен арттыру буенча эшче төркем турында**
**Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә Теләче муниципаль районында яшәүче гражданнарның социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләрен хәл итү, реаль керемнәрен арттыру буенча эшче төркем эшчәнлеген оештыру тәртибен билгели (алга таба - эшче төркем).

1.2. Нигезләмә Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

1.3. Эшче төркемнең составы һәм саны куелган бурычларны комплекслы хәл итү зарурлыгыннан чыгып билгеләнә.

1.4. Эшче төркем үз эшчәнлеген Теләче муниципаль районында Россия Федерациясе Пенсия фонды идарәсе (районара), Татарстан Республикасы буенча 10нчы Федераль салым хезмәте идарәсе, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Теләче муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге, Теләче муниципаль районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, Республика матди ярдәм үзәгенең Теләче муниципаль районындагы 41нче филиалы белән берлектә тормышка ашыра.

## 2. Эшче төркемнең максатлары һәм бурычлары

*Максатлары:*

2.1. Гаиләләр арасында проблемаларны ачыклау, аларны хәл итү юлларын билгеләү, аз керемле гражданнар Реестрында - «ярлылар реестры»нда булган гражданнарның реаль керемнәрен арттыру.

2.2. Гражданнарның реаль керемнәрен арттыру һәм ярлылар санын 2 тапкырга киметү.

*Бурычлар:*

2.3. Аз керемле гражданнар Реестрына - «ярлылар реестры»на кертелгән гражданнар турында мәгълүматны ай саен яңарту.

2.4. Эшче төркемнең утырышларын, «ярлылар реестрына» кертелгән гаилә әгъзаларын чакырып, атнага 2 тапкыр уздыру.

2.5. Чакырылган гаилә әгъзаларына гаиләнең «аз тәэмин ителгәнлек» хәленнән чыгу вариантларын, шул исәптән шәхси ярдәмче хуҗалыкны

үстерү өчен дәүләт программаларын тәкъдим итү, «минем салым» (һөнәри керемгә салым) сынау проекты буенча хокукларын гамәлгә ашыру буенча аңлатмалар бирү.

2.6. Гамәлдәге программалар кысаларында халыкның эш белән тәэмин итү үзәге аша аз керемле гражданнар Реестрына кертелгән гаилә әгъзаларын яңадан укыту.

2.7. Ай саен нәтиҗәле «социаль контракт» төзү юлы белән мохтаҗ гаиләләргә, аз керемле гаиләләргә һәм гражданнарга ярдәм күрсәтү.

## 3. Эшче төркемнең эш регламенты

3.1. Эшче төркем утырышларын атнага 2 тапкыр, сишәмбе һәм җомга көннәрендә үткәрү.

3.2. Утырышларны үткәрүнең якынча вакыты 9.00 сәгатьтә.

3.3. Утырыш үткәргәннән соң 3 көн эчендә эшче төркем беркетмәләрен төзү.

Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның «24» июль
443 номерлы карары белән
расланган 2нче кушымта

**Теләче муниципаль районында яшәүче гражданнарның социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләрен хәл итү, реаль керемнәрен арттыру буенча эшче төркем составы**

Эшче төркем рәисе:

Миннигулов И.Ә. - Җитәкче урынбасары - Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш һәм инвестиция эшчәнлеге бүлеге начальнигы.

Эшче төркем рәисе урынбасары:

Нурмөхәмәтов А.Ә. - Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары.

Эшче төркем сәркатибы:

Каюмова Л.С. - Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Теләче муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге консультанты (килешү буенча).

Эшче төркем әгъзалары:

Галимова Ф.М. - Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Теләче муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге начальнигы (килешү буенча);

Галимҗанов А.М. - Теләче муниципаль районындагы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге директоры (килешү буенча);

Нигъмәтҗанов Ф.В. - Республика матди ярдәм үзәгенең Теләче муниципаль районындагы 41нче филиалы мөдире (килешү буенча);

Галимҗанов Р.А. - Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш һәм инвестиция эшчәнлеге бүлеге баш белгече;

Мугтасимов М.М. - Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы Саба районындагы идарәсенең (районара) клиентлар хезмәте

җитәкчесе (килешү буенча);

Кашапова А.Х. - «Родник» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәгенең гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү бүлеге социаль эш буенча белгече (килешү буенча);

Шиһабетдинов И.С. - РФ Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 10нчы номерлы районара инспекциясенең баш дәүләт салым инспекторы (килешү буенча);

Теләче муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча).